ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2025ел № 10216

Башкарма комитетның «Спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмалар җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 560 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы дәүләт оешмалары һәм Татарстан Республикасының спорт әзерлеге буенча дәүләт үзәкләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 25 сентябрендәге 853 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 17 сентябрендәге 708 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмалар җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2025 елның 30 гыйнварындагы 560 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2025 елның 2 июнендәге 3961 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмалар җитәкчеләренең һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

- 2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

2 бүлек. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләренең база окладын билгеләү

6. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар хезмәткәрләренең база оклады түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| Педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Физик культура инструкторы | 27 390 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-оештыручы | 27 500 |
| | Тренер-укытучы | |
| | Инструктор-методист | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Педагог-психолог | 27 650 |
| | Өлкән тренер-укытучы | |
| | Өлкән инструктор-методист | |
| Структур бүлекчәләр җитәкчеләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Структур бүлекчә: кабинет, лаборатория, бүлек, бүлекчә, сектор, укыту-консультация пункты, укыту (укыту-производство) мастерское һәм гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыручы башка структур бүлекчәләр мөдире (башлыгы) | 27 830 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Гомуми белем бирү программасын һәм балаларга өстәмә белем бирү программасын тормышка ашыручы аерымланган структур бүлекчә мөдире (башлыгы) | 27 890 |

7. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның мәдәният хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| 1 | 2 |
| «Урта звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» | |

| | |
|---|---|
| һөнәри квалификация төркеме | |
| Аккомпаниатор | 27 450 |
| «Әйдәүче звено мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Тавыш операторы | 28 000 |
| Рәссам-бизәүче | |

8. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның медицина хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| «Урта медицина һәм фармацевтика персоналы» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | Шәфкать туташы (медбрат) | 27 760 |
| | Массаж буенча шәфкать туташы (массаж буенча медбрат) | |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | Өлкән шәфкать туташы (өлкән медбрат) | 29 630 |
| «Табиблар һәм провизорлар» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Табиб-белгечләр (өченче һәм дүртенче квалификация дәрәҗәсенә кертелгән табиб-белгечләрдән тыш) | 32 090 |

9. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның физик культура һәм спорт хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Вазыйфа исеме | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Беренче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Спорт залы буенча дежур | 25 650 |
| | 1 төркем инвалид спортчыны озатып йөрүче | |

<table>
<tr><td rowspan="2">Икенче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Спортчы</td><td rowspan="2">25 650</td></tr>
<tr><td>Әйдәүче спортчы</td></tr>
<tr><td colspan="3">Икенче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме</td></tr>
<tr><td rowspan="5">Беренче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Адаптив физик культура инструкторы</td><td rowspan="5">26 600</td></tr>
<tr><td>Спорт инструкторы</td></tr>
<tr><td>Спортчы-инструктор</td></tr>
<tr><td>Тренер-җайдак</td></tr>
<tr><td>Спорт техникасыннан файдалану һәм аны ремонтлау буенча техник</td></tr>
<tr><td rowspan="4">Икенче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Тренировка процессы администраторы</td><td rowspan="4">26 610</td></tr>
<tr><td>Адаптив физик культура инструктор-методисты</td></tr>
<tr><td>Адаптив физик культура тренер-укытучысы</td></tr>
<tr><td>Хореограф</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Өченче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист</td><td rowspan="2">26 620</td></tr>
<tr><td>Адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы</td></tr>
<tr><td colspan="3">Өченче дәрәҗә физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркеме</td></tr>
<tr><td>Беренче квалификация дәрәҗәсе</td><td>Аналитик (спорт төрләренең төркеме яки төре буенча)</td><td>26 690</td></tr>
</table>

10. Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешмаларның авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмдә билгеләнә:

<table>
<tr><th>Квалификация дәрәҗәсе</th><th>Вазыйфа исеме</th><th>Аена база окладының күләме, сум</th></tr>
<tr><td>1</td><td>2</td><td>3</td></tr>
<tr><td colspan="3">«Икенче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме</td></tr>
</table>

| | | |
|---|---|---|
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Ветеринария фельдшеры | 27 390 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | Үсемлекләрне саклау буенча агроном (урта квалификация) | |
| «Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Агроном | 27 450 |
| | Зоотехник | |
| | Ветеринария табибы | |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | II категорияле агроном | 27 500 |
| | II категорияле зоотехник | |
| | II категорияле ветеринария табибы | |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | I категорияле агроном | 27 570 |
| | I категорияле зоотехник | |
| | I категорияле ветеринария табибы | |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | Әйдәүче агроном | 27 670 |
| | Әйдәүче зоотехник | |
| | Әйдәүче ветеринария табибы | |
| «Өченче дәрәҗә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | Баш агроном | 29, 0400»; |

- 4 бүлектә 1-3 нче таблицаларның 24, 41 пунктларын төшереп калдырырга;
- 50 пунктта 25 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«25 нче таблица

Спорт өзерлеген гамәлгә ашыручы оешмалар җитәкчеләрнең база окладлары һәм башкарыла торган эшләренең сыйфаты өчен стимуллаштыру характерындагы түләүләр күләме

| Җитәкченең хезмәтенә түләү төркеме | Күләм курсәткеченең зурлыгы (дәүләт йөкләмәсе нигезендә агымдагы елның 1 сентябренә | База оклады, сум | Башкарыла торган эшләрнең сыйфаты өчен стимуллаштыру |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| | шөгыльләнүчеләр саны), кеше | | характерындагы түләүләр, сум |
| 1 | 0 - 200 | 36 300 | 4 840 |
| 2 | 201 - 400 | 38 720 | 6 050 |
| 3 | 401 - 700 | 43 560 | 6 050 |
| 4 | 701 - 1 200 | 44 770 | 7 260 |
| 5 | 1 201 - 1 800 | 48 400 | 8 470 |
| 6 | 1 801 һәм аннан да югары | 50 820 | 9 680 |

--------------------------------

<*> Спорт әзерлеген гамәлгә ашыручы оешма (спорт-адаптация мәктәбе) укучылары контингенты 3 коэффициенты белән исәпкә алына.»;

2) Спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмаларның эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

- 2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2 бүлек. Спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмаларның эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладларын билгеләү

4. Спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмаларының эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләренең һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗә эшчеләрнең гомумтармак һөнәрләре» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |

| | |
|---|---|
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 010 |

5. Спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең база окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Квалификация дәрәҗәсе | Аена база окладының күләме, сум |
|---|---|
| «Беренче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 25 650 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 25 870 |
| «Икенче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 26 030 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 26 220 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 26 420 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 26 660 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 26 870 |
| «Өченче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 27 080 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 27 300 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 27 560 |
| Дүртенче квалификация дәрәҗәсе | 27 780 |
| Бишенче квалификация дәрәҗәсе | 28 000 |
| «Дүртенче дәрәҗә хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфалары» һөнәри квалификация төркеме | |
| Беренче квалификация дәрәҗәсе | 29 040 |
| Икенче квалификация дәрәҗәсе | 29 260 |
| Өченче квалификация дәрәҗәсе | 29 480 |

6. Хезмәткәрнең вазыйфасы һәм һөнәре спорт әзерлеге буенча өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыручы муниципаль оешмаларның эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләре гомумтармак һөнәрләре, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфалары һөнәри квалификация төркемнәренең квалификация дәрәҗәләренә туры килүе федераль башкарма хакимият органының норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.

7. Берьюлы ике урында эшләү тәртибендә, шулай ук тулы булмаган эш вакыты шартларында эшләүче хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләү эшләнгән вакытка яки башкарылган эш күләменә пропорциональ рәвештә башкарыла. Хезмәт хакын билгеләү төп вазыйфа өчен, шулай ук берьюлы ике урында эшләү һәм тулы булмаган эш вакыты өчен һәр вазыйфа өчен аерым башкарыла.».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов